*Мәктәп туры*

РУС ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ
ТАТАР ТӨРКЕМНӘРЕНДӘ БЕЛЕМ АЛУЧЫ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН
**ТАТАР ТЕЛЕННӘН ОЛИМПИАДА БИРЕМНӘРЕ**
(2023-2024 нче уку елы)
**4 нче сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 60 минут**
**Максималь балл – 32**

**I. Тестлардан дөрес җавапны билгеләгез.**

1. Парсыз саңгырау тартык авазны билгеләгез. **(2 балл)**
   а) [й]
   ә) [һ]
   б) [л]
   в) [җ]

2. Хәреф белән аваз саны туры килмәгән сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) көньяк
   ә) өчпочмак
   б) икмәк
   в) елга

3. Өч иҗектән торган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) куян
   ә) аю
   б) арыслан
   в) бүре

4. *Кыю* сүзенең синонимын билгеләгез. **(2 балл)**
   а) батыр
   ә) тирән
   б) данлыклы
   в) матур

5. Ясалма сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) балык
   ә) яулык
   б) байлык
   в) күлмәк

6. Төшем килешендәге исемне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) өстәлнең
   ә) өстәлгә
   б) өстәлдән
   в) өстәлне

7. Сыйфатны билгеләгез. **(2 балл)**

а) җепшек

ә) урман

б) йөгерә

в) мин

8. Хикәя җөмләне билгеләгез. **(2 балл)**

а) Бүген син ничәдә кайтасың?

ә) Киемнәреңне пычратма!

б) Мин бүген китапханәгә кердем.

в) Стадионда балалар күпме?

## II. Теоретик бирем.

Төшеп калган сүзләрне языгыз. **(5 балл)**

[ғ] – ____________ тартык аваз. [ә] – нечкә ____________ аваз. *-ның/-нең* ____________ килеше кушымчасы. *Мин, син, ул* – ____________ алмашлыклары. *Укый* – ____________ заман хикәя фигыль.

## III. Гамәли-иҗади бирем.

1. Җөмләләрне татар теленә тәрҗемә итеп языгыз. **(5 балл)**

*Сегодня воскресенье. Мама испекла торт. Я помыла посуду. Бабушка вязала варежки. Папа читал книгу.*

2. Сез ял көннәрен ничек үткәрдегез? Шул хакта 6 җөмлә языгыз. **(6 балл)**